РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Гагарина ул., д. 13 а, д.Айдарово, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Гагарин ур., 13 а нче йорт, Айдар авылы, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318091 ОГРН 1061675010825 ИНН/КПП 1619004436/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 14 «25» июль 2019 г.

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Айдар авылы, Ленин ур. Авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стенды;
- Айдар авылы, Ленин ур. шәхси эшмәкәр “Хакимова” кибете янында мәгълүмат стенды;
- Субаш авылы, М.Җәлил ур. шәхси эшмәкәр “Хакимова” кибете янында мәгълүмат стенды;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Айдар авылы, Ленина урамы, 39нчы йорт, Айдар авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Айдар авыл җирлеге мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Айдар авыл җирлеге Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Хазиев